ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЯКУШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ЯКУШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ НУРЛАТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ          Якушкино ав.          БОЕРЫК

01.02.2021          № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегендә гарантияле исемлек нигезендә җирләү хезмәтләренең кыйммәтен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 73 номерлы карары нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче һәм 2нче кушымта нигезендә 6424,98 сум күләмендә билгеләргә һәм 2021 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2020 елның 31 гыйнварындагы 1 нче номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге территориясендә мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://nurlat.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Якушкино авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе          Х.Х.Хәмидуллин

Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 1 февралендәге 1 номерлы карарына 1 нче кушымта

2021 елның 1 февраленнән ТР Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе
Православие йоласы

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны китереп бирү | 2 340,33 |
| 3. Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 944,51 |
| 4. Җирләү хезмәте (кабер казу һәм җирләү ) | 3 140,14 |
| Барлыгы | **6 424,98** |

Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 1 февралендәге 1 номерлы карарына 2 нче кушымта

2021 елның 1 февраленнән ТР Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе

Мөселман йоласы

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе<br><br>(сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү (төрү) | 1 112,58 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле әйберләрне бирү һәм китерү | 1 227,75 |
| 4. Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 944,51 |
| 5. Җирләү хезмәте (кабер казу һәм җирләү ) | 3 140,14 |
| Барлыгы | **6 424,98** |